ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясен формалаштыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 147 статьясындагы 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясен формалаштыру турында хәбәрнамә текстын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе составына билгеләп кую өчен хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалар кандидатуралары хакындагы тәкъдимне гомумиләштерергә һәм 2017 елның 13 сентябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына бәяләмә тапшырырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.А. Ратниковага йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2017 елның 4 июле
№ 1855-V ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2017 елның 4 июлендәге
1855-V ДС номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясен формалаштыру турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы

ХӘБӘРНАМӘСЕ

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең вәкаләтләр чоры тәмамлануга бәйле рәвештә һәм "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең яңа составы формалаша башлый.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе составына билгеләп кую өчен кандидатуралар турында тәкъдимнәр (Россия Федерациясе гражданының күрсәтелгән комиссия составына керүгә язмача килешүе белән) әлеге хәбәр рәсми басылып чыккан көннән 30 көн дәвамында кабул ителә. Күрсәтелгән тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына эш көннәрендә 9 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча җибәрелә: 420060, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1 нче йорт.